**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА**
**Урсаевского сельского поселения**
**Азнакаевского муниципального**
**района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай муниципаль районы**
**Урсай авыл**
**җирлеге Советы**
**БАШЛЫГЫ**

ул. Центральная, д. 65, село Урсаево,
Азнакаевского муниципального района, 423318
Тел. (факс) (8-85592) 35-0-36

Үзәк урам, 65, Урсай авылы
Азнакай муниципаль районы, 423318
Тел. (факс) (8-85592) 35-0-36

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«07» ноябрь 2019 ел № 2

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Мөслим торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Уставы белән, **карар чыгарам:**

1. 23.11.2019 ел Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Мөслим торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

1.2. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Мөслим пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы-Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Башкарма комитеты;
- гражданнар җыенын үткәрү вакыты – 23 ноябрь 2019 ел 11.00 сәг.тән 12.00 сәг.кадәр;
- үткәрү урыны – Мөслим авылы, Гафури ур. , 31 йорт, Мөслим авыл мәдәният йорты залы ;

1.3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2019 елның 14 дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Урсай авылы, Үзәк урамы, 60 йорт;
- сайлау хокукына ия булган Мөслим торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;
- Мөслим торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнар җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә;

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Урсай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 350 сум күләмендә, 2 төркем инвалидлардан түләүне киметеп, аны 175 сум (50%) күләмендә билгеләп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- юлларга щебенка җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү) Такташ ур.,Мөслим авылы;
- Мөслим авылында урамнарны яктырту, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, энергияне саклый торган лампаларны урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү;
- Мөслим авылында территориядә җыештыру, көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чарларны вакытлыча җыю, чистарту;
- Мөслим авылында юлларны кардан чистарту;
- Мөслим авылында җәй көне территорияне чабу;
- Мөслим авыллында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материал, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эш өчен түләү);
- Мөслим авыллында артезиан скважиналарына насослар сатып алу.
- Мөслим авылында урам күрсәткечләрен ике телдә ясау һәм урнаштыру.

« РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Мөслим авылы, Такташа ур., 10 йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

Башлык И.А.Абдуллин

УРСАЕВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ
ИНН 1602002416
КПП 164301001